# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында

1 статья. Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, № 1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 3) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәҗбүри медицина иминлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, мәҗбүри медицина иминлеге системасында социаль гаделлеккә һәм тигезлеккә ирешү, республиканың бөтен территориясендәге гражданнарга күрсәтелә торган медицина ярдәменең күләмен һәм сыйфатын тигезләү өчен шартлар тудыру максатларында Республика сырхауханә кассасы төзелә. Республика сырхауханә кассасы эшчәнлегенә аның идарәсе һәм даими эшләүче башкарма органы - башкарма директор җитәкләүче башкарма директорлык җитәкчелек итә. Республика сырхауханә кассасы идарәсе составына Татарстан Республикасы халык депутатлары, башкарма хакимият органнары вәкилләре, һөнәр берлекләренең республика органнары вәкилләре, иминләштерү оешмаларының, иминләштерүчеләрнең һәм медицина учреждениеләренең вәкилләре керә. Сырхауханә кассасы идарәсенең составы һәм аның рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.».

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

3 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 20 декабре
№ 547